**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 2 сентябрь № 609

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 45 һәм 46 статьяларына дәүләт граждан хезмәтендә елларның озынлыгын тәртипкә китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 2 июль, ФЗ-176 нчы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Дәүләт хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен түләүле өстәмә ялга хокук бирә торган стажны исәпләү һәм аларга акчалата түләүне сакламыйча озак вакытлы ял бирү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 1997 ел, 1 апрель, 274 нче карары;

«Эш көннәре нормаланмаган Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренә еллык түләүле өстәмә ял бирү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2005 ел, 29 декабрь, 667 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 667 нче карары белән расланган Эш көннәре нормаланмаган Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренә еллык түләүле өстәмә ял бирү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында» 2006 ел, 13 ноябрь, 535 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков